
Терлекчелек - авыл хужалыгы олкәсенен тотрыклы рәвештә керем бирә торган тармакларыннан берсе. Шул тармакта Ләмберә авылында туып-vскән Рустам белән Радмила Неваевлар хезмәт итәләр; авыллары, Мордовия авыл хужалыгы vсешенә зур олеш кертәләр.
Рустам белән Радмила Неваевлар әниләре Динара Рәстәм кызы белән бергә яшиләр. Кон саен иртәнге алтынчы яртыда торалар, ә сәгать 7дә алар эш урынында - «Нива» дигән сот-товар фермасынын терлекчелек корпусларынын берсендә. Икесе дә - терлекчеләр, гадирәк әйткәндә, терлекләрне карау буенча эшчеләр. Бер ишегалдында эшлиләр, анда кара-чуар токымлы 130лап савым сыеры асрала. Егерме сигез яшьлек Рустам белән 21 яшьлек Радмила Неваевларнын бvгенге тормышы комсомолецларнын энтузиазмына һәм дәртенә охшаган. Эш шунда ки, аларнын мостәкыйль тормышы Ләмбернен 1нче урта мәктәбен тәмамлаганнан сон, асылда, шулай ук колхоздан башланган, ләкин башка исем астында – «Нива» жәмгыяте. Тогәлрәк әйткәндә, бу авыл хужалыгы предприятиесенен Ләмберә бvлегеннән, анда бvген крестьян гаиләләреннән чыккан кешеләр генә тvгел, ә Саранск халкы да унышлы эшли. Ләмберә кырларында һәм фермаларында игенчеләр, терлекчеләр, инженерлар һәм механизаторлар булып эшлиләр.
«Нива»да барлыгы 360 баш сыер бар. Бик кvп сот бирvчеләр. Kvз алдыгызга китерегез, узган ел аларнын һәркайсы уртача 8 мен 300 килограммнан артык биргән. Быел коллектив бу кvрсәткечне узып китәргә ниятли. Терлекче һонә-ренә Радмила тиз генә килми: тормышта еш була торганча, бу очраклы эш иде. Бервакыт ул абыйсы янына фермага барып, анын анда нәрсә белән шогыльләнvен, кеше телендә гади сыерлар белән ничек ягымлы аралашуын карады. Ростәмне кvзәткәндә, кыз сыерларнын аны ярты сvздән vк анлауларын кvреп алды: алар турында кайгыртуга акрын гына могрәп жавап бирәләр һәм телләре белән кулларын яларга тырышалар. Ойгә кайткач, Радмила катгый рәвештә әнисенә: «Мин дә фермага эшкә барам!» Абыйсы сенеле ниятен хуплады. Шулай итеп ул «Нива»да савым сыерларын карау буенча эшче булып эшкә урнаша. Ә бит ул вакытта ана нибары 18 яшь кенә булган. Ә эш шулай була: 2019 елда Ләмбернен 1нче урта мәктәбенен 9нчы сыйныфын тәмамлагач, Радмила хокук академиясендә укуын дәвам итv һәм югары белемле юрист булу очен, документларын

Урта Идел институты каршындагы Саранск коллиятенә тапшыра. Ләкин ике елдан сон кызнын планнары кинәт vзгәрә һәм ул коллияттә укуын туктата. Язмыш ана башка ориентир кvрсәтә - башта фермада абыйсы белән акча эшләргә ниятли, ә аннары янадан юридик белем турындагы хыялына кайта.
- Башта фермада мина жинел булмады, - дип искә ала Радмила Неваева. - Бу юнәлештә алга таба бара алмам дип уйладым. Ләкин vземне кулга алдым, бер-ике атна эшләдем, беренче чын хезмәт хакын алдым – һәм минем ботен шикләрем берьюлы юкка чыкты. Остәвенә, терлекче һонәрен vзләштерvдә мина абыем Рустам генә тvгел, ферманын башка хезмәткәрләре дә, шул исәптән анын модире А.В.Наточеев та актив ярдәм итте. Хезмәт коллективында мин бик тиз игътибарны һәм ярдәмне тойдым. Бу намуслы хезмәт итәргә, барысы белән бергә ахыргы хезмәт нәтижәләре очен кайгыртырга зур этәргеч булды.
Радмила белән Рустам vз ишегалдындагы һәр сыерны номерлары буенча компьютер кебек беләләр. Хезмәттәшләре Неваевлар гаилә династиясе вәкилләрен “терлекче һонәрендә аяклар ашаталар” дип шаярталар, чонки кvп йорергә, терлекләрне карарга кирәк. Әмма ин моһиме - хайваннарны тырышып карау: сыерлар астыннан тиресне вакытында чистартырга, аны механик транспортерга кадәр кvчерергә, жимлекләрдән ашалмаган азык калдык-ларын жыярга, махсус жайланмалы трактор аларны ботен ишегалдына сибеп жибәргәннән сон азык оемнәрен (печән, сенаж һәм кукуруз силосы) тозәтергә һәм башкалар. Абыйлы-сенелле Рустам белән Радмила Неваевлар бvген нәрсә турында хыяллана дип сорасагыз - бертавыштан диярлек: «Яна елга сугышсыз керергә, егетләребез жинv белән кайтырга тиеш.»

*Наилэ НАСЫРОВА эзерлэде*